**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Федотовка авыл җирлеге**
**Федотовка авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге Федотовка авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, 500 сум сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Федотовка авыл җирлеге Федотовка авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту;

-җирлекнең суүткәргеч милеген расланган исемлеккә туры китереп су үткәрү мөлкәтен карап тоту;
- МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча түләү)
- Федотовка авыл мәдәният йорты өчен тавыш көчәйтү комплекты сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 8 (авыл мәдәният йорты), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (авыл клубы) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Федотовка авыл җирлеге башлыгы В.И.Павлова